ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«СУГУШЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«СУГЫШЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Центральная ул., дом 27, село Сугушла,
Лениногорский район, 423281

Центральный урамы, 27 нче йорт, Сугышлы
авылы, Лениногорский район, 423281

Тел.: (8-85595) 3-81-91, факс: (8-85595) 3-81-91, Sugush.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 31 октябре № 5

Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 12 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Сугышлы авыл җирлеге Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 нче группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрдән, кендезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме::

а) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Юлтимер торак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) урам утларына техник хезмәт күрсәтү;

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, иске авария агачларын кисү (килешү буенча эшләрне түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

б) авыл җирлеге торак пункты чикләрендә автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:

- Юлтимир торак пункты юлларын кардан чистарту (Совет ур., Игтисамовлар ур.);

- Юлтимерторак пунктында (Совет ур., Игтисамовлар ур.) юлдагы чокырларны ремонтлау ямау

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урам, 27 йорт адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы А.П. Зыятдинова